ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2016 ел № 13/9

Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 номерлы карары белән хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 елның 24 августындагы 678 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/8 номерлы карары белән хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге 9/8 номерлы Карары редакциясендә), кушымтада каралганча, 12 таблицаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге Карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев